ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Транспорт салымы турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Транспорт салымы турында» 2002 елның 29 ноябрендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2002, № 11; 2003, № 7, № 11; 2004, № 11; 2005, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4; 2008, № 7 (I өлеш); 2009, № 11; 2010, № 10 (II өлеш); 2014, № 3, № 6, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«$3^1$. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, муниципаль район территориясендә урнашкан индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендәге инфраструктура объектларыннан файдалана торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы белән индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзегән кече һәм урта эшкуарлык субъектлары салым салынудан азат ителәләр.

Салым ташламасы индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзелгән датага индустриаль парк (сәнәгать паркы) мәйданының иң күбе 70 проценты биләнгән булу шарты үтәлгәндә бирелә һәм индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзелгән айдан соң килүче айның 1 числосыннан башлап мондый килешүнең гамәлдә булу срогына, әмма иң күбе 10 елга кулланыла.

Индустриаль парк (сәнәгать паркы) территориясендә эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                 Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 28 апрель
№ 26-ТРЗ